ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«7» 11 2020 г. № 225

**Муниципаль контроль төрләренең һәм аларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеген һәм формаларын алып бару тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын *яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге* 294-ФЗ *номерлы Федераль* законның 6 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы **карар бирә:**

1. Расларга:

1.1. Кушымта нигезендә муниципаль контроль төрләренең һәм аларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеген алып бару тәртибен.

1.2. *Муниципаль контроль төрләренең һәм аларны* Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының формаларын алып бару тәртибен.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы башлыгының
2020 елның «7» 11 2020
225 номерлы карарына
1 нче кушымта

## Муниципаль контроль төрләренең һәм аларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеген алып бару тәртибе

1. Муниципаль контроль төрләренең һәм аларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеген алып бару тәртибе (алга таба - Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген формалаштыру һәм алып бару процедурасын билгели (алга таба - исемлек).

2. Муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеге әлеге Тәртипнең кушымтасында билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан раслана, төзелә һәм алып барыла.

3. Контроль төрләре исемлеге үз эченә түбәндәге мәгълүматны ала:

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төренең атамасы;

2) муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыру вәкаләтләре бирелгән Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары исемнәре;

3) тиешле җирле үзидарә органнарына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында Балтач муниципаль районының муниципаль норматив хокукый актының исеме һәм реквизитлары.

4. Контроль төрләре исемлегенә үзгәрешләр түбәндәге очракларда кертелә:

1) муниципаль контрольнең яңа төрен кертү яки муниципаль контроль төрен төшереп калдыру кирәк булган очракта;

2) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны регламентлаштыручы норматив хокукый актлар реквизитларын төгәлләштерү максатларында;

3) муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы исеме үзгәрүгә бәйле рәвештә.

5. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы Балтач район башкарма комитетына муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны регламентлаштыручы һәм әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләргә үзгәреш кертә торган норматив хокукый акт үз көченә кергән көннән алып 5 эш көне эчендә контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләр кертү турында тәкъдим җибәрә. Муниципаль контрольне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы юкка чыгарылган очракта, контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдим юкка чыгарыла торган җирле үзидарә органы вәкаләтләре йөкләнгән җирле үзидарә органына җибәрелә.

6. Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимне карый һәм әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына тәкъдим килгән көннән алып 10 көннән дә артык булмаган вакытта контроль төрләре Исемлегенә үзгәрешләр кертә.

7. Контроль төрләре Исемлегенә кертелгән мәгълүмат һәркем файдалана алырлык. Контроль төрләре Исемлеге Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

Муниципаль контроль төрләренең һәм аларны
Татарстан Республикасы Балтач муниципаль
районы территориясендә гамәлгә ашыруга
вәкаләтле җирле үзидарә органнарының
исемлеген алып бару Тәртибенә кушымта

(Үрнәк форма)

## Муниципаль контроль төрләренең һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарының исемлеге

| т/б № | Җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре | Муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме | Тиешле җирле үзидарә органына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен бирү турында норматив-хокукый акт реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | | | |